ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

06.04.2021 г. Заинск № 202

**“Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында” 2013 елның 20 сентябрендәге 2078 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында”**

Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалар тәрбияләүче гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү максатларында, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. “Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында” 2013 елның 20 сентябрендәге 2078 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карары (Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 27.01.2014 ел, №157, 10.02.2014 ел, № 253, 12.10.2015 ел, № 1792, 26.04.2016 ел, № 777, 21.03.2017 ел, № 466, 24.01.2018 ел, № 73, 04.09.2009 ел, № 472, 03.02.20021 ел, 55 нче номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) белән расланган "Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен бирү тәртибе” кушымтасында «Гомуми нигезләмәләр» бүлегенең 1.3 пункты икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җан башына уртача кереме 20,0 мең сумга кадәр булган гаиләләргә мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында балаларны тәрбияләгән һәм караган

өчен ата-аналар (законлы вәкилләр) түләвенең бер өлешенә өстәмә компенсация билгеләгәндә гаиләнең бер кешегә туры килә торган уртача кереме аны билгеләү турында гариза биргән айдан алдагы алты календарь айга кадәрге соңгы унике календарь ай өчен керемнәре суммасыннан чыгып исәпләнә.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2021 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.В. Чапковка йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Л.Р. Печина
3-27-42